РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
РУКОВОДИТЕЛЬ ИСПОЛНИТЕЛЬНОГО КОМИТЕТА ЧУРАКАЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АКТАНЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

423746, село Чуракаево,
ул. Советская, дом 69,
Тел. 3-44-65

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЧУРАКАЙ АВЫЛ ЖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ ЖИТӘКЧЕСЕ

423746, Чуракай авылы, Совет ур.,
69 нчы йорт. Тел.3-44-65

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**«18»апреля 2025 года**

**КАРАР**
**№ 7**

«Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башкарма комитеты 11.02.2013 ел 3 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Норматив хокукый актларны гамәлдәге законнарга туры китерү максатларында Актаныш муниципаль районының Чуракай авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. «Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге башкарма комитетында муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе турында» Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районы Чуракай авыл җирлеге Башкарма комитеты 11.02.2013 ел 3 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 3.2 бүлегенең 2.11 пунктында "документлардан" сүзеннән соң "һәм (яисә) мәгълүматтан"сүзләрен өстәргә;

1.2. 4 бүлекнең 2-6 абзацларын үз көчләрен югалткан дип таныргa;

1.3. 4 бүлекнең 7 абзацында ", шулай ук административ регламентлар проектларында бәйсез экспертиза нәтиҗәләрен исәпкә алуны бәяләүне" сүзләрен төшереп калдырырга.;

1.4. Тәртипнең 2 бүлегенең 7 пунктындагы 4 абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе субъекты дәүләт хакимияте башкарма органнарының, җирле үзидарә органнарының административ регламентлары проектларын эшләү һәм килештерү Россия Федерациясе субъектының дәүләт хезмәтләре реестрын, муниципаль хезмәтләр реестрын тиешенчә электрон рәвештә алып баруны тәэмин итә торган дәүләт мәгълүмат системасында һәм (яисә) муниципаль мәгълүмат системасында

гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Хокукый мәгълүматның рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Актаныш муниципаль районының рәсми сайтында "авыл җирлекләре" бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Чуракай авыл җирлеге
Башкарма комитет җитәкчесе Р.Р.Хайдаров